ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ _113_ от «_03_» _10_____ 2018 г.

Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның башка түләүле эш башкару нияте турында эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) хәбәр итү тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 ел, 2 мартында кабул ителгән ФЗ-25 Федераль законнының 11 маддәсе, 2 бүлеге нигезендә, Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның хезмәт дисциплинасын ныгыту, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу максатларында, к а р а р б и р ә м:

1. Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның башка түләүле эш башкару нияте турында эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) хәбәр итү тәртибен (алга таба –Тәртип) расларга (теркәлеп килә).

2. Мамадыш муниципаль районы Советының кадрлар белән эшләү һәм муниципаль хезмәт секторына:

2.1. Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларны биләүче затларны һәм муниципаль хезмәткәрләрне расланган Тәртип белән таныштырырга.

2.2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе В.Н. Фәизовка йөкләргә.

Район башлыгы А.П. Иванов

Мамадыш муниципаль
районы Башлыгының
03.10.2018 ел, 113 нче санлы
карарына кушымта

**Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның башка түләүле эш башкару нияте турында эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) хәбәр итү**

**ТӘРТИБЕ**

1.Әлеге тәртип Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазифаларны биләүче затларның башка түләүле эш башкару нияте турында эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) хәбәр итү тәртибе (алга таба – Тәртип) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 ел, 2 мартында кабул ителгән ФЗ-25 Федераль законнының 11 маддәсе, 2 бүлеге нигезендә, хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу максатларында эшләнгән һәм муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазифаларны биләүче затларның башка түләүле эш башкару нияте турында эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) хәбәр итү эшчәнлеген, формаларын һәм тәртибен билгели.

2. Муниципаль хезмәткәр, башка вазифаны биләүче зат эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) алдан язмача хәбәр итү юлы белән бүтән түләүле эш башкарырга хокуклы, әгәр бу мәнфәгатьләр каршылыгына китермәсә һәм законда башкасы каралмаган булса.

3. Муниципаль хезмәткәр, башка вазифаны биләүче зат эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) башка түләүле эш башкару нияте турында элеге эштә эшли башлаганчы алдан язма рәвештә хәбәр итә, яңа урнашкан муниципаль хезмәткәрләр – муниципаль хезмәткә билгеләнгән көнне.

4. Башка түләүле эш башкару нияте турында эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) хәбәр итү (алга таба- хәбәрнамә), әлеге Тәртип буенча, 1 нче кушымта нигезендә муниципаль хезмәткәр, муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан төзелә.

5. Муниципаль хезмәткәр һәм муниципаль вазифа биләүче затлар, хәбәрнамәне җитәкче (эш бирүче) исеменә җибәрәләр.

6. Хәбәрнамәләрне теркәү кадрлар секторының җаваплы вазифаи затлары тарафыннан муниципаль вазифа биләүче затларның, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең әлеге тәртип буенча 2 нче кушымта нигезендә башка түләүле эш башкару нияте турында хәбәрнамәләрне теркәү журналларына кергән көнне гамәлгә ашырыла.

7. Теркәлгән Хәбәрнамә кәгазенең күчермәсе билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәр һәм муниципаль вазыйфа биләүче затка бирелә яки почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән җибәрелә. Муниципаль хезмәткәр һәм муниципаль вазифа биләгән затка тапшырылырга тиешле хәбәрнамә күчермәсенә билдерү датасы һәм теркәлү номеры белән "теркәлгән" тамгасы куела.

8. Кадрлар секторының җаваплы вазифаи затлары, теркәлгәннән соң 3 эш

көне эчендә резолюция өчен эшкә алучының вәкиленә (эш бирүчегә) хәбәрнамә җибәрәләр. Хәбәрнамә эшкә алучы вәкиленең (эш бирүченең) резолюциясе белән муниципаль хезмәткәр һәм муниципаль вазифа биләүче затның шәхси эшенә теркәлеп куела.

9. Әгәр дә эшкә алучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан башка түләүле эш башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималы булуны карый икән, ул бу турыда муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан башка түләүле эш башкарган очракта мәнфәгатьләр каршылыгы булу яки булмау фактын билгеләү буенча муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенә хәбәрнамә белән мөрәҗәгать итә.

10. Эшкә алучы вәкиленең (эш бирүче) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү ихтималы булу турындагы тәкъдимне карап, тикшерү нәтиҗәләре буенча, муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче зат тарафыннан башка түләүле эш башкару мөмкинлеге булу яки муниципаль хезмәт башкару белән бәйле чикләүләрне үтәмәү белән бәйле рәвештә башка түләүле эшне башкару мөмкин булмау турында тиешле карар кабул итә.

11. Муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе, муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче затларның башка түләүле эшне башкара алу яки башкара алмау турындагы хат проекты эшкә алучы вәкиле (эш бирүче) исеменә җибәрелә.

Тәртипкә 1нче № кушымта

______________________________________________

______________________________________________

(эшкә алучы вәкиленең (эш бирүче) биләгән вазифасы,Ф.И.Ә.и

___________________________________________

___________________________________________(

муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль вазифа биләүче затның биләгән вазифасы,Ф.И.Ә.и

# Хәбәрнамә

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 ел, 2 мартында кабул ителгән ФЗ-25 Федераль законнының 11 маддәсе, 2 бүлеге нигезендә , мин, ____________________________________________________________

муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль вазифа биләүче затның биләгән вазифасы,Ф.И.Ә.и

сезгә үземнең елдан башка түләүле эштә эшләү нияте барлыгын хәбәр итәм.

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль вазифа биләүче затның башкарырга ниятләгән эшчәнлек турында белешмәләр: башка төрле түләүле эшнең төре, предметы, вазыйфаи бурычлары)

_____________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Оешманың аталышы һәм юридик адресы, оешма җитәкчесенең Ф.И.Ә и.)

____________________________________________________________________

(хезмәт килешүе, гражданлык-хокукый килешүе һ. б..)

Күрсәтелгән эшне башкару мәнфәгатьләр каршылыгына китереп чыгармаячак.

Эшне башкарганда "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында»2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәргә йөкләмә бирәм.

"__" _______ 20_____ ел ___________________/____________________

(имза) (Ф.И.Ә.и.)

«Таныштым»

________________________________ ___________________/____________________

(җирле үзидарә җитәкчесенең вазифасы, Ф.И.Ә.и)

«хәбәрнамә теркәлде» "__" _______ 20_____ ел

________________________________ ___________________/____________________

(хәбәрнамәне алучы җаваплы затның вазифасы, (имза) (Ф.И.Ә и.)

Тәртипкә 2нче №лы кушымта

# Журнал
## регистрации уведомлений муниципальных служащих и лиц, замещающих муниципальные должности, о намерении выполнять иную оплачиваемую работу

| Теркәү датасы | хәбәрнамә бирүче муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче затның ФИӘи | Хәбәрнамә алучы муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче затның ФИӘи | Резолюциянең кыскача эчтәлеге һәм датасы | Хәбәрнамәне алучының имзасы | Хәбәрнамәне карау нәтиҗәсе буенча муниципаль хезмәткәр яки муниципаль вазифа биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе мәгълүматы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |